**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«18» ноябрь, 2020 ел № 1692

«2021 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020 елның 13 декабрендәге 1671 номерлы башкарма комитет җитәкчесе карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Беренче абзацта «2016 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 23 сентябрендәге 698 номерлы карары (2015 елның 30 декабрендәге 1009 номерлы үзгәрешләр)» сүзләрен «2021 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «1.2 пунктының 1.2.2 пунктчасында «7 сум 70 тиенгә кадәр» сүзләрен «8 сум 00 тиенгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.3.3 пунктының 1.3.2 пунктчасында «ата-ана взносын җыю - 24 сум 30 тиен» сүзләрен «ата-ана взносын җыю - 24 сум 00 тиен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.В. Хәбибуллин